РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре,
423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

2022 елның 4 феврале № 3

Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 39 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 23.1 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 39 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 2 нче кушымтадагы таблицаның 2 нче юлында «0,39» цифрлы кыйммәтен «1,0» цифрлы кыйммәтенә алмаштырырга;

карарга 5 нче кушымтаның 1 пунктында:

беренче абзацның икенче җөмләсендә «хезмәткәрне» сүзен «даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затны,» сүзләренә алмаштырырга;

беренче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга шулай ук Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм хезмәткәрләренең тулы вәкаләтле вәкилләре арасында төзелә торган социаль партнерлыкның территориаль-тармак килешүендә каралган нигезләр буенча һәм күләмнәрдә матди ярдәм түләнергә мөмкин.»;

карарга 17 нче кушымтаның 1 пунктына икенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга аларның гаризасы нигезендә шулай ук Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм хезмәткәрләренең тулы вәкаләтле вәкилләре арасында төзелә торган социаль партнерлыкның территориаль-тармак килешүендә каралган нигезләр буенча һәм күләмнәрдә матди ярдәм түләнергә мөмкин.»;

2. Түбән Кама муниципаль районы Советының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә әлеге карарның үтәлешен тәэмин итәргә.

3. «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет һәм финанслар департаменты» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама шәһәре Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры
вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары М.В.Камелина